КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 апрель г.Казань № 493

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри үстерүгә дәүләт заказын формалаштыру тәртибе турында» 2010 ел, 25 июнь, 519 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 1 июль, 528 нче; 2015 ел, 20 декабрь, 1028 нче; 2018 ел, 21 декабрь, 1205 нче; 2019 ел, 30 март, 244 нче һәм 2020 ел, 13 февраль, 105 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), преамбуладагы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт заказы турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-599 номерлы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һөнәри белем бирү чараларына дәүләт заказы турында» 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-252 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруның үрнәк регламентын раслау турында» 2015 ел, 28 август, 631 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыруның үрнәк регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентын раслау турында» 2016 ел, 14 март, 140 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 25 май, 343 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1080 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәгариф өлкәсендә җитәкче кадрлар резервын формалаштыру регламентының 6 пунктындагы бишенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт биреме кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларын тормышка ашыру тәртибен раслау турында» 2018 ел, 13 декабрь, 1120 нче карары белән расланган Дәүләт биреме кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларын тормышка ашыру тәртибенә, 2 пункттагы «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары системасын төзү һәм аның эшләве турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1260 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 сентябрь, 836 нчы; 2022 ел, 4 июнь, 520 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары исемлегендә:

таблица башисеменең 2 графасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар оештыру һәм үткәрү регламентында:

1 бүлектә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте дәүләт органнарында (алга таба – башкарма хакимият органнары)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарында» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

икенче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

өченче абзацта тиешле килешләрдәге «башкарма хакимият органы» сүзләрен тиешле килешләрдәге «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «башкарма хакимият органнарын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарын» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «башкарма хакимият органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 бүлекнең беренче абзацында «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекнең беренче абзацында «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары турындагы бертип нигезләмәдә:

2 бүлектә:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яисә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органы (алга таба – башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы, төп оешма)» сүзләрен «республика

башкарма хакимият органы яисә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органы (алга таба – җирле үзидарә органы, төп оешма)» сүзләренә алмаштырырга, «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

5.1 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органында» сүзләрен «республика башкарма хакимият органында» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.2 пунктчада «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның 5.2.2 пунктчасында:

бишенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты указлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указлары» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында (алга таба – башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарында, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органнары)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин